**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА НОВОИГАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯНА ИГЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Иглай ав. **КАРАР**

«10» ноябрь 2023 ел № 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Тукай поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елның 23 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта авыл тукталышы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлегенең Тукай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.

2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, лицензияләү, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итүгә;

- Тукай п. чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

- Тукай п. территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Яңа Иглай авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Ханәфиев